Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Уразлы авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

2025 елның 27 ноябре № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Уразлы авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1.2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлегенең Уразлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар) тыш, 1000,00 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Уразлино авылы, Тынычлык урамы, 7 йорт, административ бина; шулай ук кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Уразлы
авыл җирлеге башлыгы: М.Г.Хамидуллин